# ИКЕ АККОШ

*БӘХТИ ГАЙСИН музыкасы*
*ӘХСӘН БАЯН сүзләре*

Һаваларда оча ике аккош,
Каурыйлары җиргә коела.
Янып сөйсәң, күңел канатлана,
Мәңге талмас кебек тоела.

Һаваларда очкан ике аккош
Аерылмыйча яшәр гел бергә.
Без очарбыз бәхет киңлегендә
Синең белән икәү гомергә.

Һаваларда очкан ике аккош
Талгын гына канат кагына.
Әллә нигә бергә чакларда да
Күңелем һаман сине сагына.

Һаваларда оча ике аккош,
Еракларга китә моңнары.
Киләчәккә аккош юла булып
Китсен безнең яшьлек еллары.